ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.05.2020 Алабуга шәһәре №___22_

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль
районында кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү
мәсьәләләре буенча эшче төркем төзү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем төзергә (алга таба-эшче төркем).
2. Расларга:
   2.1. Алабуга муниципаль районындагы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем составы, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә.
   2.2. Алабуга муниципаль районындагы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем турында нигезләмә, 2 нче кушымта нигезендә.
3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Эшче төркемнең эшчәнлеге турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында даими урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарны эш төркеменең барлык әгъзаларына таратуны оештырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Сөнгатуллина З.Х.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
“______” _______ ____ел
карарына 1 анче кушымта

**Алабуга муниципаль районындагы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем с оставы**

Эшче төркем рәисе:
Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм проектлар буенча җитәкчесе урынбасары.

Эшче төркем рәисе урынбасары:
Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеш палатасы рәисе.

Эшче төркем секретаре:
Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасының баш белгече (бүлек башлыгы)

Эшче төркем әгъзалары:

1. Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы рәисе
2. Алабуга муниципаль районының Хокук палатасы рәисе
3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы
4. Алабуга муниципаль районы Советының авыл җирлекләре белән эшләү секторы мөдире
5. Алабуга муниципаль районы җирлеге башлыклары (килешү буенча).
6. ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы вәкиле (килешү буенча).
7. Алабуга муниципаль районы эшкуарлар Советы рәисе (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
“______” _______ ____ел
карарына 1 а нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъекты мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Рәис | |
| Нургаянов Л. Ф. | ТР АМР Башкарма комитетының икътисад һәм проектлар буенча җитәкчесе урынбасары |
| Рәис урынбасары | |
| Никонов Т. В. | АМР перспективалы социаль-икътисади үсеш палатасы рәисе |
| Секретарь | |
| Зарипова Е.В. | АМР перспективалы социаль-икътисади үсеш палатасының баш белгече |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Гыйззәтуллин И. С. | АМР Җир-мөлкәт палатасы рәисе |
| Гатин С. Р. | АМР Хокук палатасы рәисе вазыйфаларын башкаручы |
| Волкова О. В. | АМР Башкарма комитетының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы |
| Ковалева Н.П. | АМР Советының авыл җирлекләре белән эшләү буенча сектор мөдире |
| | АМР җирлеге башлыклары (килешү буенча) |
| Вахитов Т.Р. | ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы вәкиле (килешү буенча) |
| Драгун Д.И. | АМР эшкуарлар Советы рәисе (килешү буенча) |

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы — Сөнгатуллина З.Х.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
“_____” ______ ____ел
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем турында Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1. 1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Эшче төркем киңәшмә консультатив органы булып тора.

1.3. Эшче төркем эшчәнлегенең максаты:

- «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209 -ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба- 209 - ФЗ номерлы Федераль Закон) нигезләмәләрен гамәлгә ашыруның иң уңай практикаларына нигезләнгән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (алга таба - КУЭ субъектлары) мөлкәти ярдәм чараларына бертигез дәрәҗәдә ирешү максатларында бердәм ярдәм итүне тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт (муниципаль) мөлкәте исемлекләрен (алга таба – Исемлекләр) тулыландыру өчен чыганакларны ачыклау;

1.4. Эшче төркем үз эшчәнлегендә 209-ФЗ номерлы Закон һәм башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.5. Эшче төркем үз эшчәнлеген аның әгъзаларының тигез хокуклылыгы, карарлар кабул итүнең коллегиальлеге һәм хәбәрдарлыгы принципларында башкара.

**2. Эшче төркемнең бурычлары һәм функцияләре**

2.1. Алабуга муниципаль районы территориясендә КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне координацияләү.

2.2. КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү.

2.3. Алабуга муниципаль районы территориясендә КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча еллык һәм квартал планнар төзү.

2.4. Исемлекләрне тулыландыру чыганакларын ачыклау максатында муниципаль милек составын анализлау нәтиҗәләре буенча алынган мәгълүмат нигезендә түбәндәгеләр башкарыла:

а) муниципаль предприятиегә яки учреждениегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән казна объектлары һәм милек турында, шул исәптән файдаланылмый яки билгеләнеше буенча нәтиҗәсез файдаланыла торган, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә (файдалы файдалану срогы биш елдан ким булган торак урыннардан һәм предметлардан тыш), хуҗасыз һәм башка милеккә муниципаль милек реестрларыннан белешмәләр, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр, архивлардан өземтәләр, мөлкәт турында башка документлар соратып алу;

б) Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль күчемсез милек объектларын, шул исәптән җир кишәрлекләрен әлеге тикшерүне уздыруга вәкаләтле орган тарафыннан тикшерү;

в) муниципаль милекне арендага алу белән кызыксынучы КУЭ субъектларының тәкъдимнәре.

2.5. Исемлекләрне тулыландыру турында җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгатьчелек, КУЭ субъектларыннан кергән тәкъдимнәрне карау.

2.6. Алабуга муниципаль районы территориясендә КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү кысаларында тәкъдимнәр әзерләү, шул исәптән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

а) мөлкәт ярдәменә җәлеп ителә торган мөлкәт Исемлеген формалаштыру һәм тулыландыру, составын киңәйтү;

б) КУЭ субъектлары Исемлегенә кертелгән һәм кирәкле булмаган объектларны башка милеккә яки аларны башка файдалану буенча алмаштыру (КУЭ субъектларының мөлкәт составын, мөрәҗәгатьләр санын, аренда шартнамәләрен төзү хокукына сатулар нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча);

в) Алабуга муниципаль районы территориясендә КУЭ субъектлары өчен мөлкәт, муниципаль преференцияләр бирүнең ташламалы шартларын билгеләү;

г) КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне норматив хокукый җайга салу, шул исәптән әлеге ярдәмне алу тәртибен гадиләштерү;

д) КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы хакимият органнары (җирле үзидарә органнары) эшчәнлегенең нәтиҗәлелек күрсәткечләрен эшләү;

е) КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм турында мәгълүмат бирүне тәэмин итү;

ж) муниципаль милекне исәпкә алу, аның турында мәгълүматларны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм актуальләштерү тәртибен камилләштерү;

з) муниципаль милек белән идарә итү буенча расланган программаларга КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү механизмнарын камилләштерүгә, шулай ук мондый ярдәмне киңәйтү өчен гавами-хокукый берәмлекнең мөлкәти потенциалын файдалануга юнәлдерелгән чаралар кертү.

2.7. Алабуга муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгълүмати һәм консультация ярдәме күрсәтү, шул

исәптән КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча укыту ярдәмендә.

## 3. Эшче төркемнең хокуклары

Әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында эшче төркем хокуклы:

3.1. Үз утырышларында эшче төркем компетенциясе нигезендәге мәсьәләләрне карарга, тиешле карарлар кабул итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, Алабуга муниципаль районы җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, Татарстан Республикасында дәүләт милке белән идарә итү буенча Федераль агентлыкның төбәкара территориаль идарәсеннән эшче төркем компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга.

3.3. Эшче төркем эшенә башкарма хакимиятнең кызыксынган органнары, җирле үзидарә органнары, КУЭ субъектлары, фәнни, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен, шулай ук башка белгечләрне җәлеп итәргә.

3.4. Муниципаль күчемсез милек объектларын тикшерү өчен вәкаләтле органнарга тикшерү үткәрү һәм (яки) өстәмә мәгълүмат бирү тәкъдим ителә торган күчемсез милек объектлары исемлеген җибәрергә.

## 4. Эшче төркемнең эшчәнлек тәртибе

4.1. Эшче төркем эшче төркем рәисеннән, эшче төркем рәисе урынбасары, эшче төркем секретаре, эшче төркем әгъзаларыннан һәм эшче төркем 10 кешедән тора.

4.2. Эшче төркем утырышларында чакырылган кызыксынган затлар, шул исәптән КУЭ субъектлары вәкилләре тавыш бирү хокукы белән катнаша ала.

4.3. Эшче төркем утырышлары көндезге яки көндезге-читтән торып (шул исәптән видео-конференц-элемтә аша) үткәрү рәвешендә кирәк булган саен, әмма ярты елга кимендә 1 тапкыр үткәрелә.

4.4. Эшче төркем секретаре эшче төркем утырышының көн тәртибе, утырышны үткәрү датасын, вакытын, урынын һәм эшче төркем утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча материалларны утырышны уздыру датасына кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча эшче төркем әгъзаларына җибәрә.

4.5. Эшче төркем утырышын эшче төркем рәисе яисә аның кушуы буенча эшче төркем рәисе урынбасары алып бара.

4.6. Эшче төркем рәисе:

- эшче төркем эшчәнлеген оештыра;
- эшче төркем утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында карар кабул итә;
- эшче төркем утырышының көн тәртибен һәм аның эш тәртибен раслый;
- эшче төркем утырышларын алып бара;
- эшче төркем утырышында мәсьәләләрне карау тәртибен билгели;
- эшче төркем эшчәнлегенең оператив мәсьәләләре буенча карар кабул итә;
- эшче төркем утырышлары беркетмәләренә кул куя.

4.7. Эшче төркем секретаре:

- эшче төркем утырышын әзерләү белән бәйле оештыру чараларын гамәлгә ашыра;
- эшче төркем утырышы көн тәртибен эшче төркем әгъзалары игътибарына җиткерә;
- утырышларны үткәрү вакыты һәм урыны турында эшче төркем әгъзаларына хәбәр итә;
- эшче төркем утырышлары беркетмәләрен төзи;
- эшче төркемнең эш башкаруын алып бара;
- эшче төркем утырышларына материалларны, шулай ук аның карарлары проектларын әзерләүне оештыра.

4.8. Эшче төркем әгъзалары:

- эшче төркем утырышының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертә;
- эшче төркем утырышларында һәм аларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышуда катнашалар;
- эшче төркем карарларын әзерләүдә һәм кабул итүдә катнашалар;
- эшче төркем утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча эшче төркем секретаренә материаллар тапшыралар.

4.9. Эшче төркем утырышы, әгәр анда эшче төркем әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 1/2 өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

4.10. Эшче төркем кворумы булмаганда, эшче төркем утырышы кабат чакырыла.

4.11. Эшче төркем әгъзалары аның утырышларында алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Эшче төркем әгъзасы булмаганда, ул карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен тапшырырга хокуклы.

4.12. Эшче төркем әгъзалары эшче төркем утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча башка фикер белдерергә хокуклы, ул эшче төркем утырышы беркетмәсенә кертелә яки беркетмәгә язма рәвештә теркәлә.

4.13. Тавыш биргәндә эшче төркемнең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Эшче төркем карарлары, эшче төркем әгъзаларының билгеләнгән вакытка бирелгән язма фикерләрен исәпкә алып, эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм эшче төркем утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Эшче төркем утырышында катнашучыларның башка фикере булган очракта, ул беркетмәгә кушыла һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора. Тавыш биргәндә тавышлар саны тигез булса, эшче төркем рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.14. Эшче төркем рәисе карары буенча утырыш читтән торып үткәрелергә мөмкин. Утырышны читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрү турында карар кабул иткәндә, эшче төркем әгъзаларына эшче төркем секретаре тарафыннан мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә, шул ук вакытта читтән торып тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча утырышны читтән торып үткәрү турындагы карарда күрсәтелгән вакытка кадәр нигезләнгән фикерләрен тапшыралар.

4.15. Читтән торып тавыш бирүне уздырганда карар тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Шул ук вакытта читтән торып тавыш бирүдә катнашучы әгъзалар саны эшче төркем әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 булырга тиеш. Тавышлар тигез булган очракта, эшче төркем җитәкчесе тавышы хәл итүче булып тора, ул булмаганда эшче төркем җитәкчесе урынбасары тавышы хәлиткеч була.

4.16. Эшче төркем карарлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен тәкъдим итү характерына ия.

4.17. Эшче төркем утырышы беркетмәсе эшче төркем утырышы уздырылганнан соң 2 эш көне эчендә эшче төркем секретаре тарафыннан рәсмиләштерелә, эшче төркем рәисе тарафыннан имзалана.

4.18. Эшче төркем утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- эшче төркем утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;
- беркетмә номеры;
- эшче төркем утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашкан эшче төркем әгъзалары исемлеге, шулай ук эшче төркем утырышына чакырылган затлар исемлеге;
- эшче төркем утырышында каралган һәр мәсьәлә буенча кабул ителгән карар;
- эшче төркем утырышында каралган һәр мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләре.

4.19. Эшче төркем утырышы беркетмәсенә эшче төркем каравына тапшырылган материаллар кертелергә тиеш.

## 5. Эшче төркем эшчәнлеген техник- оештыру

5. Эшче төркем эшчәнлеген техник- оештыру ягынннан тәэмин итүне Арча муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Эшче төркем әлеге карарның 1 нче кушымтасында билгеләнгән составта даими нигездә эшли